**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ
ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 4 Урыссу штп от 19 .03.2018 ел

2018 елга Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
фаразланган планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 13.06.2007 ел, № 24 карары, 75 статьясы,белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы поселогы муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында" Нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында 2018 елга күчемсез муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.
2. Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетына 2018 елга «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) гамәлгә ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны кеше хокуклары, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы -
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе Р.М. Нуриев

Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Советы карары белән расланды

**2018 елга**
**«Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы»**
**муниципаль берәмлегенең муниципаль**
**мөлкәтен ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ФАРАЗЛАНГАН ПЛАНЫ**
**(ПРОГРАММАСЫ)**

## I бүлек. 2018 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары

2018 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 22.07.2008 ел, № 159-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 13.06.2007 ел, №24 карары белән расланган «Урыссу шәһәр тибындагы поселогының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аны файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында» Нигезләмәсе нигезендә эшләнде.

2018 елда муниципаль мөлкәткә идарә итү системасының базар икътисады шартларында барлыкка килә торган өлеше буларак муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерү, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 159-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне һәм муниципаль милектәге арендалана торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2018 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан җирлек бюджетына салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- мөлкәтне карап тотуга җирлек бюджетыннан чыгымнарны киметү.

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге мөлкәтен хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә аның икътисадында структур үзгәрешләр түбәндәге сәбәпләр буенча көтелми:

- хосусыйлаштыруга тәкъдим ителгән бинада милекчене алмаштырганда муниципаль берәмлектә икътисадый хәлгә җитди йогынты ясарга сәләтле җитештерү урнаштырылмый.

Милекне сату исәбенә район бюджетына якынча 0,3 млн. сум алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның Фаразланган планы (программасы) нигезендә, сатуга планлаштырыла торган объектның якынча бәясе базар бәяләве уздырганнан соң төгәлләштерелергә тиеш.

Хосусыйлаштырылырга тиешле объектның фаразланган якынча бәясе базарның конъюнктурасыннан чыгып исәпләнгән.

2018 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

## II бүлек. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2018 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәте

| № т/б | объект | адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Фаразланган сату вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Кибет (билгеләнеше - торак булмаган, 1 кат, мәйданы 31,6 кв.м, кадастр №16:43:100128:391) | ТР, Ютазы районы, Урыссу ш.т.п., Жуков ур., 6 й. | ачык аукцион | 1 квартал | Билгеләнеше буенча файдаланылмый |